КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 ноябрь г.Казань № 1266

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетын 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә ашыра башларга.

2. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторларына:

Татарстан Республикасы бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр керүне тәэмин итү, шулай ук аларны түләү бурычларын киметү буенча чаралар күрергә;

квартал саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән срокларда һәм формада ай саен керемнәр керү фаразларын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертергә;

квартал саен, Татарстан Республикасы бюджетының керемнәр буенча факттагы үтәлешенең фараздан тайпылу сәбәпләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасы бюджетының керемнәр өлешендә үтәлеше турында аналитик материалларны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән срокларда кертергә;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең ведомство буйсынуындагы администраторлары исемлеген билгеләү турында норматив хокукый актлар кабул итүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәренең тиешле бюджет классификациясе кодларына күчерү максаты белән ачыкламаган керемнәрне оператив рәвештә тәгаенләүне гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре чыганаклары реестрын булдыру һәм алып бару өчен кирәкле мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинеты тарафыннан раслана торган тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары вәкаләтләре һәм (яки) алар тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре составы үзгәргән очракта, аларга үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны вәкаләтләргә һәм (яки) идарә ителә торган керемнәр составына үзгәреш кертә торган закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертергә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторына квартал саен, элек бирелгән бюджет кредитларын каплау өчен каралган акчаны кире кайтару суммаларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгының эчке һәм тышкы финанслау чыганаклары акчасын ай саен җәлеп итү һәм каплау фаразларын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән срокларда һәм формада кертергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына бу карарның 2 пунктындагы өченче, дүртенче һәм җиденче абзацларында һәм 3 пунктында каралган мәгълүматка охшаш булган җирле бюджетларның үтәлеше турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.

5. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2023 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган, максатчан билгеләнешкә ия булган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертлар (алга таба – максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара трансфертлар) (финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Президенты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган бюджетара трансфертлардан тыш) 2023 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасының баш администраторы тарафыннан 2022 елда файдаланылмаган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында (булмау турында) карар кабул итү, шулай ук аларга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә аларны элек бирелгән бюджетка кире кайтару, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты акчасының баш администраторы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә формалаштырылган һәм кертелгән, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып әлеге бюджетара трансфертлар торган тиешле бюджет чыгымнары турындагы хисап нигезендә гамәлгә ашырыла;

бу пунктның өченче абзацында күрсәтелгән срокны үтәү максатларында, Татарстан Республикасы бюджеты акчасының баш администраторлары бу пунктның өченче абзацында каралган хисапларны карап тикшерүне һәм 2022 елда файдаланылмаган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карарны әлеге акча Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килештерүгә җибәрүне тәэмин итә;

2022 елда файдаланылмаган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карар әлеге бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артмаган күләмдә кабул ителә:

Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан кабул ителгән, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып максатчан билгеләнешкә ия бюджетара трансфертларның калган өлешләре торган һәм үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре булганда;

әгәр 2023 елда файдаланылмаган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара трансфертлар бирелгәндә элегрәк билгеләнгән максатларга туры килә торган максатлар өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирү каралмаса һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып максатчан билгеләнешкә ия бюджетара трансфертларның калган өлешләре торган җирле бюджет акчасын алучы тарафыннан алынган һәм үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре булса;

Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләре 2023 елның 1 февраленә кадәр түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә:

2022 елда аларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итүгә бирелгән субсидияләрнең калган өлешен дәүләт йөкләмәсендә билгеләнгән һәм ирешелмәгән күрсәткечләргә туры килә торган күләмдә. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр дәүләт йөкләмәләре үтәлеше турындагы хисаплар нигезендә әлеге акчаның калган өлешләрен кире кайтаруны контрольдә тотуны тәэмин итә;

аларга Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә бирелгән, 2023 елда шул ук максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булуы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланмаган субсидияләрнең калган өлешен;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр тарафыннан федераль башкарма хакимият органнарына бирелә торган бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисаплар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелергә тиеш;

социаль-мәдәни өлкә һәм торак-коммуналь хуҗалык объектларын дәүләт милкеннән муниципаль милеккә тапшыру, агымдагы елда тапшырылган объектларның эшләвен финанслар белән тәэмин итү чыганагын билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Бу карарга теркәлгән Максатчан билгеләнешкә ия булган, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган, 2023 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучының бюджетара трансфертларны күчерү вәкаләтләре Татарстан Республикасы бюджет акчасы белән баш эш итүчеләр тарафыннан алар кабул иткән карарлар нигезендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырыла торган бюджетара трансфертлар исемлеген расларга.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына:

2023 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетының чыгымнар буенча үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертергә;

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын бюджет законнарында билгеләнгән срокларда «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерүне тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт заказчыларына, шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт казна учреждениеләренә 2023 елның 15 гыйнварына кадәр 2022 елда Татарстан Республикасы исеменнән товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән дәүләт контрактлары шартлары нигезендә түләнергә тиешле әлеге дәүләт контрактлары өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган өлешләре буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына мәгълүмат кертергә.

9. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2023 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләре хезмәткәрләренә файдаланылмаган ял өчен акчалата компенсация Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле органнарын, Татарстан Республикасының дәүләт казна учреждениеләрен тотуга бюджет сметаларында хезмәт өчен түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә;

торгларда катнашучылар тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру конкурсында, аукционында катнашуга заявкаларны тәэмин итү буларак кертелә торган акча суммасы, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алуларда катнашучылар тарафыннан Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары үтәлешен тәэмин итү буларак кертелә торган акча Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан вакытлыча эш итүгә кергән акча белән операцияләрне исәпкә алу өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында аларның үзләре ачкан шәхси счетларында исәпкә алына;

товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түләнергә тиешле шартнамәләр (дәүләт контрактлары) төзегәндә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар аларга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түбәндәге аванс түләүләрен күздә тотарга хокуклы:

шартнамә (дәүләт контракты) суммасының 100 процентына кадәр, әмма ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаган күләмдә – басма матбугатка язылу һәм аларны сатып алу турындагы, элемтә, кабель һәм спутник телевидениесе хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча, ягулык-майлау материаллары, транспорт чаралары, юлламалар, авиация, тимер юл, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында йөрү өчен билетлар, ашыгыч кирәкле медикаментлар (кеше тормышына куркыныч янаган хәлләрдә кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү өчен таләп ителә торган медикаментлар) сатып алуга шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча, квалификация күтәрү курсларында

белем алу турындагы, яңадан һөнәри әзерлек узу турындагы, фәнни, методик, фәнни-гамәли һәм башка конференцияләрдә катнашу турындагы, проект документациясенә һәм инженерлык тикшеренүләренә дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы, капиталь төзелеш объектларының смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү, аларны реконструкцияләү яки техник җиһазландыру турындагы шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча, транспорт чаралары хуҗаларының граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре буенча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан чит ил оешмалары белән төзелә торган Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданнарын дәвалау, мәгълүмат белән тәэмин итү, пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү турындагы шартнамәләр буенча, янгын сүндерү чараларын үткәрү турындагы шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча, учреждение эшчәнлегенең уставта каралган төп төрләрен тәэмин итү максатларында товар-матди кыйммәтләр сатып алуга шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча, яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү максатларында медицина әйберләре, медицина куллану материаллары, махсус кием, индивидуаль саклану чаралары һәм дару препаратлары сатып алуга шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча;

шартнамә (дәүләт контракты) суммасының 90 процентыннан артмаган, әмма иң күбе житкерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары күләмендә – дару чаралары, медицина әйберләре, дәвалану туклануы буенча махсуслаштырылган продуктлары, дезинфекцияләү чаралары, иммунобиологик препаратлары белән тәэмин итү турындагы шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча (бу пунктның бишенче абзацында каралган очраклардан тыш);

шартнамә (дәүләт контракты) суммасының 50 процентыннан артмаган, әмма иң күбе ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары күләмендә – әгәр дә башкасы Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, калган шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр (дәүләт контрактлары) төзегәндә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар үзләренә билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә аванс түләүләрен шартнамә (дәүләт контракты) суммасының 50 процентыннан алып 90 процентына кадәр, әмма җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаган күләмдә күздә тоталар – «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына федераль бюджет турында» Федераль закон нигезендә финанс белән тәэмин итү акчасы казначылык тарафыннан күзәтчелек ителергә тиешле шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча;

юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү 2023 елда Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла;

2024 елның 1 гыйнварына кадәр түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

хезмәт өчен түләү буенча бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән тәртиптә расланган лимитларын башка максатларга каралган бюджет йөкләмәләре лимитларын (хезмәт өчен түләү буенча акча бирүгә исәпләүләрне түләүгә бюджет йөкләмәләре лимитларыннан тыш) киметү исәбенә арттыру (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары хезмәткәрләрен эштән азат иткәндә түләүләрне башкару максатларында бюджет йөкләмәләре лимитларын арттырудан тыш);

хезмәт өчен түләү буенча акча бирүгә исәпләүләрне түләүгә бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән тәртиптә расланган лимитларын башка максатларга каралган бюджет йөкләмәләре лимитларын (хезмәт өчен түләү буенча бюджет йөкләмәләре лимитларыннан тыш) киметү исәбенә арттыру (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары хезмәткәрләрен эштән азат иткәндә түләүләргә исәпләүләрне түләү максатларында бюджет йөкләмәләре лимитларын арттырудан тыш).

10. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына:

2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегендә билгеләнгән күләмдә бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турындагы хәбәрнамәләрне Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләргә җиткерергә;

2023 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы исеменнән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2022 елда түләнергә тиешле әлеге дәүләт контрактларына түләү өчен файдаланылмаган, 2023 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең калган өлеше суммасы чикләрендә бюджет ассигнованиеләре күләмнәре турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә;

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамә (муниципаль контракт) булганда муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнарга тотыла торган субсидияләрне, башка бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә күчерүне гамәлгә ашырырга:

аванс өчен шартнамәдә (муниципаль контрактта) билгеләнгән күләмдә түләүгә;

эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне, товар кайтартуны раслый торган документлар булганда шартнамә (муниципаль контракт) буенча башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр, кайтартылган товар өчен түләүгә.

11. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр:

аларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Татарстан Республикасы бюджетының расланган җыелма бюджет исемлеге күрсәткечләре нигезендә бюджет йөкләмәләре лимитларын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән ведомство буйсынуындагы эш итүчеләр һәм (яки) аларны алучылар арасында бүләргә;

максатчан билгеләнешкә ия бюджетара трансфертлар бирелгәндә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә бюджетлар арасындагы исәп-хисаплар буенча хәбәрнамә җиткерергә;

2023 елның 15 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган башка бюджетара трансфертлар (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^5$ статьясындагы 4 пунктының 1 – 7 пунктчаларында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлардан тыш) бүленешен раслау турындагы норматив хокукый актлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне тәэмин итәргә;

2023 елның 15 февраленә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^4$ һәм $44^5$ статьялары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүләр төзүне тәэмин итәргә.

12. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1 нче кушымтада бирелгән карарларының гамәлдә булуы 2023 елга озайтыла;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2 нче кушымтада бирелгән, финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән карарларының һәм карарлары нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр туктатыла.

13. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 29 ноябрь, 1266 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучының Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр аларны күчерү буенча вәкаләтләрен 2021 елда кабул ителгән карарлар нигезендә Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенә тапшырган максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган бюджетара трансфертлар исемлеге

| Бюджетара трансферт исеме | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Җирле үзидарә органнары тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе |
| Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (аларга үзгәреш кертү, өстәү) буенча дәүләт вәкаләтләрен финанслар белән тәэмин итү өчен бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата бүләкләү түләүне гамәлгә ашыру өлешендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |

| 1 | 2 |
|---|---|
| ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен бюджетларга субвенцияләр | |
| Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан мәгариф өлкәсендә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыру чараларын тормышка ашыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| Спорт әзерлеге оешмаларын норматив хәлгә китерү өчен спорт җиһазы һәм инвентаре сатып алу буенча муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы |
| Авыл территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыру өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Торак урын наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү (сатып алу) буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Дәүләт һәм хосусый (муниципаль-хосусый) партнерлык яисә концессия килешүләре турында килешүләр нигезендә массакүләм спорт инфраструктурасы объектларын төзүгә (реконструкцияләүгә) чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы |
| Авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыру өчен башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| Мәдәният тармагына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Халык саны 300 меңгә кадәр булган торак пунктларда муниципаль театрларның иҗади эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү һәм матди-техник базасын ныгыту өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Модельле муниципаль китапханәләр булдыру өчен бюджетларга башка бюджетара трансфертлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 29 ноябрь, 1266 нчы
карарына 1 нче кушымта

2023 елга гамәле озайтыла торган
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
карарлары исемлеге

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары:

«2005 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан социаль ярдәмнең аерым чараларын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларны тоту тәртибен раслау турында» 2005 ел, 21 март, 140 нчы;

«2006 елда гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчаларны тоту тәртибен раслау турында» 2006 ел, 16 февраль, 55 нче;

«2008 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт милкенә карый торган һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан архив документларын саклау, комплектлау, исәпкә алу һәм алардан файдалану буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2008 ел, 21 май, 329 нчы;

«2010 елда дару белән тәэмин итү өлкәсендә аерым вәкаләтләрне үтәгәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен раслау турында» 2008 ел, 26 декабрь, 923 нче;

«Дарулар куллану рецептлары буенча дару препаратлары, медицина эшләнмәләренә рецептлар буенча медицина эшләнмәләре, шулай ук инвалид балалар өчен дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән тәэмин итү буенча гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәт күрсәтүне финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибен раслау турында» 2009 ел, 20 апрель, 246 нчы.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 29 ноябрь, 1266 нчы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән, 2023 елның 1 гыйнварыннан
31 декабренә кадәр гамәлдә булуы туктатып торыла торган карарлары һәм
карарлары нигезләмәләре
исемлеге

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә социаль-икътисадый үсешне һәм иҗтимагый финанслар белән сыйфатлы идарә итүне стимуллаштыру фондыннан дотацияләр бирү тәртибе турында» 2007 ел, 16 июль, 303 нче карары.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирләү урыннарын карап тоту чыгымнарын финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 ел, 18 ноябрь, 946 нчы карарындагы 3 пункты.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекле янгын сүндерүчеләргә, янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә һәм аларның гаиләләре әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү һәм аларны яклау чаралары турында» 2012 ел, 10 август, 694 нче карары.

________________________________